**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нче йорт,
тел: 4-12-91

---

**2024лның 17 ноябре** **74/1-2 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең Столбище авылы торак пунктында (Екатерина, Совет, Каретная, Энергетиклар, Столбище урамнары торак пункты территориясенең бер өлеше) 2025 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында карар**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлегенең Столбище авылы торак пунктында (Екатерина, Совет, Каретная, Энергетиклар, Столбище урамнары торак пункты территориясенең бер өлеше) гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең Столбище авылы торак пункты (Екатерина, Совет, Каретная, Энергетиклар, Столбище урамнары торак пункты территориясенең бер өлеше) территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым салу акчаларын 10000 сум күләмендә түбәндәге эшләрне эшләргә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Столбище авылы торак пунктында Совет урамының бер өлешендә, 148-150 йортлар районында һәм Екатеринин урамы буйлап юл төзү, смета нигезендә: ком, вак таш, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, эшләр өчен түләү, проект-смета документациясен төзү буенча хезмәтләр күрсәтү, техник эшләр башкаруны күзәтү, материалны лаборатор сынаулар);
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча эшләр өчен түләүгә юллау.

3. Әлеге карарны Столбище авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы:** ________________ **И.Ю.Романова**